**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2024 елның 22 октябре 1892 номер

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2027 елларга Лаеш муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү» максатчан программасын раслау турында» 2022 елның 24 июнендәге 1545 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» Федераль законның 31_1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 333-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2027 елларга Лаеш муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү» максатчан программасын раслау турында» 2022 елның 24 июнендәге 1545 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

1) 1 өлешнең 7 пунктчасына:

– ", балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауда катнашу " сүзләрен өстәргә. ".

2) 1 кисәк:

– түбәндәге эчтәлекле 20 пунктча өстәргә:

"20) территорияне төзекләндерү ".

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**